**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.12.2017 г.Казань № 01-02/170

Татарстан Республикасы
Юстиция министрлыгының
дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча таләпләрне үтәү комиссиясе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы тору турындагы законнарның үтәлешенә контрольне көчәйтү максатыннан Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 19 сентябрендәге 431 номерлы Указы һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләре буенча кайбер указларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 11 декабрендәге ПУ-1092 Указы чыгуга бәйле рәвештә, боерам:

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча таләпләрне үтәү комиссиясе турындагы Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2016 елның 13 февралендәге 01-02/49 номерлы боерыгы белән расланган нигезләмәгә, аны түбәндәге эчтәлектәге 3.4.3. пункт белән тулыландырып, үзгәреш кертергә:

«3.4.3. Әлеге Нигезләмәнең 3.2, 3.4, 3.4.1 пунктларында каралган мотивлаштырылган бәяләмәләр үз эчләренә түбәндәгеләрне алырга тиешләр:

а) мөрәҗәгатьләрдә яки белдерүләрдә әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мәгълүматны;

б) запрослар нигезендә дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынган оешмалардан алынган мәгълүматны;

в) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм белдерүләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча мотивлаштырылган нәтиҗәне, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.13, 3.15.1, 3.18 пунктлары нигезендәге карарларның берсен яки башка карар кабул итү өчен тәкъдимнәрне».

Министр Р.И. Заһидуллин